Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авылы башкарма комитеты

КАРАР

19 февраль 2026 ел № 2

Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге территориясендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Берләшкән социаль фондының Әлмәт районындагы Клиент хезмәтенең (бүлек хокукларында) 2026 елның 262 гыйнварындагы 51-34-09/131 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Миңлебай авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. № 1 нче, № 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9678,63 сум күләмендә билгеләргә.

2.Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авылы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2025 елның 5 февралендагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны торак пункт территориясендә Әлмәт районы, Миңлебай авыл җирлеге адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә; «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Миңлебай авылы
башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Рәхимов

Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авылы башкарма
комитетының 2026 елның
19 февралендәге 2 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5 635,82 |
| 3 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 908,43 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 134,38 |
| Барлыгы | | 9 678,63 |

Миңлебай авылы
башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Рәхимов

Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авылы башкарма
комитетының 2026 елның
19 февралендәге 2 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәетне кәфенләү | 3 304,27 |
| 3 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 331,54 |
| 4 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 908,44 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3134,38 |
| Барлыгы | | 9 678,63 |

Миңлебай авылы
башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Рәхимов